

Кадошкино районы Большеполянка топ гомуми белем бирv мәктәбенен туган тел һәм әдәбият укытучысы Зәйнәб Хосәен кызы Кильдеева танылган татар язучысы Габдулла Алишнын тууына 112 ел тулу унаеннан «Шигъри әкиятләр остасы» дип исемләнгән әдәби кичә vткәрде. Ул балаларны язучынын биографиясе белән таныштырды һәм анын шигырьләр, очерклар, хикәяләр, пьесалар язуы турында сойләде, әмма язучы vзенен татар әдәбияты хәзинәсенә нык кергән әкиятләре белән аеруча таныш.

Анын «Сер тотмас vрдәк», «Мактанчык чыпчык һәм тыйнак сарык», «Койрык», «Нечкәбил» әкиятләре хезмәт соючәнлек һәм игелеклелек хислә-рен тәрбияләргә, vз иленне яратырга, кыю, гадел булырга, олкәннәргә хормәт тәрбияләргә ярдәм итә.
А.Алишнын әкиятләрен искә алып, балалар чара барышында «Бу  озек кайсы әкияттән?», «Табышмаклар», «Мәкәльләр һәм әйтемнәр» әйттеләр.
Чара Габдулла Алиш әкиятләре буенча тошерелгән татар телендә мульт- фильмнар карау белән тәмамланды.

***Альфия Капкаева, математика укытучысы***